РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

30.03.2022                Буа шәһәре                № 74 Бк/к

Карарны гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлеше, 1 өлешенең 22 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 өлешенең 15 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 20210 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасының 3 пунктындагы «д» пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Буа муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2022 елның 29 гыйнварындагы 26/Бк-к номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карарын юкка чыгарырга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче                                        Л.Р. Шакирҗанов